**СОВЕТ БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Коньяк урамы,1 нче йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 Телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

---

**2024 елның 05 ноябре** **80 номер**

**КАРАР**

**Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлегенең Олы Кабан торак пунктында (Полевая тыкрыгы, Заовражная ур., Полевая ур. территориясендә) гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлеге башлыгы КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 16 ноябрендә 11.00 сәгатькә Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлегенең Олы Кабан торак пунктында (Полевая тыкрыгы, Заовражная ур., Полевая ур. территориясендә) үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

Лаеш муниципаль районы Олы Кабан авыл җирлеге Олы Кабан торак пункты территориясендә (Полевая тыкрыгы, Заовражная ур., Полевая ур. территориясендә) яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә укучы студентлардан һәм балачактан инвалидлардан тыш, 2025 елда үзара салымны 5000 сум күләмендә кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?

- каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, рөхсәтсез чүплекләрне бетерү

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында һәм Олы Кабан авыл җирлегенең рәсми сайтында кабул ителгән көннән алып биш көн эчендә игълан итәргә.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Олы Кабан**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **И.Г. Шәрәфиев**